Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылындагы
гражданнар җыены

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге составына керүче Булдырь авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 17 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү)
- евроконтейнерлар сатып алу

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 87 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 56 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 56 катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү)
- евроконтейнерлар сатып алу.

3. Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлегенең Булдырь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү)

- евроконтейнерлар сатып алу**.**

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Булдырь авыл җирлеге
башлыгы ________________ Н.Н. Воляков